Татарстан Республикасы
Кукмара муниципаль районы
Нырты авыл җирлеге Советы

Карар

2022 елның 8 сентябре №21

Нырты авыл җирлеге Советының аерым карарларын гамәлдән чыгару турында

Нырты авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Нырты авыл җирлеге Советының түбәндәге карарларын гамәлдән чыгарырга:

«Кукмара муниципаль районының Нырты авыл җирлеге территориясендә каты коммуналь калдыкларны җыю, чыгару, ташу һәм урнаштыру тәртибен раслау турында» 2016 елның 16 декабрендәге 35 номерлы карары;

«Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлеге Советының 2016 елның 16 декабре 35 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлеге территориясендә каты коммуналь калдыкларны җыю, чыгару, ташу һәм урнаштыру Тәртибенә үзгәреш кертү турында» 2018 елның 21 июнендәге 8 номерлы карары;

«Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлеге Советының 2016 елның 16 декабре 35 номерлы карары белән расланган ТР Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлеге территориясендә каты коммуналь калдыкларны җыю, чыгару, ташу һәм урнаштыру Тәртибенә үзгәреш кертү турында» 2021 елның 23 ноябрендәге 27 номерлы карары;

2. Әлеге карарны авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырып, халыкка игълан итәргә; шулай ук «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Җирлек башлыгы Котдусов Т.А.